# *РУС ТЕЛЕНДӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ 6 НЧЫ СЫЙНЫФ ТАТАР ТЕЛЕН ТУГАН ТЕЛ БУЛАРАК ӨЙРӘНҮЧЕ УКУЧЫЛАРГА " РӘВЕШ" ТЕМАСЫ БУЕНЧА  ЭШ ПРОГРАММАСЫ*

***БАШКАРДЫ:***
***ГАНИЕВА И.Р.***

***МАКСАТ:*** рус телендә белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче балаларга рәвеш сүз төркемен дөрес итеп өйрәтү тора.

***БУРЫЧЛАР*:**

- Рәвешләрне сүз төркеме буларак өйрәтү өчен эш программасын төзү, сәгатьләр бүленешен дөрес бүлү, укыту.
- Мәктәптә белем бирү процессында рәвеш сүз төркеменең кыен очракларын билгеләү.
- Уку эшчәнлеген оештырганда биремнәр, күнегүләр системасыннан файдалану, коммуникатив чараларны куллану мөмкинлекләрен, алшартларын ачыклау, эш тәҗрибәсе белән уртаклашу.



# Көтелгән нәтиҗә

Рәвеш сүз төркемен өйрәнү, аларның төркемчәләре белән танышу, аңа хас булган закончалыкларны үстерү, яңа кагыйдәләр белән танышу, морфологик анализ ясарга өйрәнү; әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү; шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү.




РӘВЕШ
тамыр һәм ясалма
төп, чагыштыру, артыклык дәрәҗәсе
6 төркемчә
фигыльгә, сыйфатка, исемгә иярә

# Рәвешләрнең мәгънә төркемчәләре




**Мәгънәләренә карап, рәвешләр 6 төркемчәгә бүленә.**

# Эш программасы

| № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт |
| 1-2 | Рәвеш. Рәвеш сүз төркеме турында төшенчә. | 2 | | |
| 3 | Рәвешләрнең ясалышы. | 1 | | |
| 4 | Рәвешләрнең ясалышын кабатлау белән бәйле сочинение: “Кышкы каникулда” | 1 | | |
| 5 | Хаталар өчстендә эш. Рәвешләрнең мәгънә төркемчәләре. Саф рәвешләр. | 1 | | |
| 6 | Охшату-чагыштыру рәвешләре. | 1 | | |
| 7 | Күләм-чама рәвешләре. | 1 | | |
| 8 | Дәрес-ярыш: “Рәвешләр” | 1 | | |
| 9 | Урын рәвешләре. | 1 | | |
| 10 | Вакыт рәвешләре. | 1 | | |
| 11 | Сәбәп-максат рәвешләре. | 1 | | |
| 12/13 | Рәвеш сүз төркемен кабатлау. | 2 | | |
| 14 | Рәвеш сүз төркеменә карата ирекле диктант. | 1 | | |








# Технологик карта

| Дәрес этаплары | Укытучы эшчәнлеге | Укучы эшчәнлеге | Универсаль уку гамәлләре (УУГ) |
|---|---|---|---|
| Оештыру, мотивлаштыру | Исәнләшу.Уңай халәт тудыру | Исәнләшу. Дәрескә әзер икәнлекләрен күрсәтү. | К:сыйныфташлар һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү |
| Өй эшен тикшерү | Презентация эше белән танышу, бәяләү | Презентация эше белән таныштыру,фикер алышуда катнашу | Р:эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү |
| Проблемалы ситуация булдыру.Уку мәсьәләсен кую | 1.199нчы күнегүнең үтәлешен күзәтү | 1.Сүзләрне төрле сүз төркемнәренә аерып язу.Өстәмә сорауларга җавап бирү | Т:төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру.<br>Р:бәйләнешле сөйләм, үз фикерләрен һәм җавапларын телдән матур, дөрес итеп әйтә белү. |
| | 2.200нче күнегү белән бәйле сораулар бирү | 2.Сорауларга җавап бирү. | |
| | 3.Слайдтан кагыйдәне укыту | 3.Кагыйдәне уку | |
| Дәрескә максат һәм бурычлар кую.Дәрес темасын ачыклау | Дәреснең темасын һәм максатын хәбәр итү | Нәтиҗә ясау | К:мәгълүмат үзара аралашу хезмәттәшлек инициативасы белән күрсәтү.<br>Т:яңа белемнәр табу |
| Яңа белемнәрне беренчел үзләштерү | 1.201нче күнегүнең биремен аңлату. | 1.Мәкальләрне дөрес итеп уку, кучереп язу, фикер алышуда катнашу. Өстәмә сорауларга җавап бирү,нәтиҗә ясау. | Т:үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.<br>Р:биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү |
| | 2.Слайдтан кагыйдәне уку | 2.Кагыйдәне уку,үзе ясаган нәтиҗә белән чагыштыру | |
| Ял минуты | | | |
| Яңа белемнәрне ныгыту | 203нче күнегүнең биремен аңлату,җавапларны тыңлау | Рәвешләрнең синонимнарын яисә антонимнарын табып язу, җөмләләр уйлау | Т:үзеңнең белем системасында ориентлаша белү.<br>Р:биремнәрне үтәүнең дөреслеген тикшерү |
| Өй эше | Өй эшенә бирелгән 204нче күнегүнең биремен аңлату | Бүген- бу көн мисалында биремне эшләп карау | Р:үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, үзконтроль |
| Рефлексия, бәяләү, үзбәя | Эшчәнлеккә нәтиҗә ясау, өйрәнелгән материалны анализлау | | |

# *1 нче кыен очрак*

Укучылар еш кына рәвешне сыйфат белән билгелиләр, бигрәктә җөмләдә исемне ачыклап килү очракларында. Мәсәлән: ***Укучылар дәрестә татарча-русча сүзлекләрне файдаландылар.*** Бу җөмләдә *татарча-русча* рәвеш исемне ачыклап килгән һәм укучыларга сүзнең тамырына сүз ясагыч кушымча (-ча) ялгануына игътибар итәргә кирәк.



# *2 нче кыен очрак*

Татар телендә рәвеш сүз төркеменең грамматик категориясе юк һәм бу – татар теленең рус теленнән сизелерлек аермасын тәшкил итә. Шуның нәтиҗәсе буларак, әлеге сүз төркемен аеруда кыенлык тудыра, шуңа күрә рәвеш ясагыч кушымчаларны (-ча/-чә, -дай/-дәй, -лата/-ләтә һәм башка) истә тоту мөһим.



# 3 нче кыен очрак

Башка сүз төркемнәре (исем, сыйфат, фигыль, сан, алмашлыкның кайбер төркемчәләре (зат һәм сорау алмашлыклары) башлангыч сыйныфларда ук өйрәнелә башлый, ә рәвеш сүз төркеме буларак алтынчы сыйныфта гына үзләштерелә. Шул сәбәпле укучылар аларны телдән һәм язма сөйләмдә чагыштырмача азрак, сирәгрәк кулланалар. Нигездә вакыт һәм урын рәвешләре белән генә чикләнәләр: бүген, иртәгә, кичә, ерак, якын һәм башкалар.



# Күнегү


кызу
салмак
тиз
кышын
синоним
әкрен
антоним
синоним
җәен
антоним
синоним
тәмам
антоним
Татар телендә синоним һәм антоним рәвешләр була. Һәр рәвешнең дә
синоним яисә антоним пары булмый!

# Уен


Кушымча ялганып ясалган рәвешләр
-ча/-чә
-дай/-дәй, -тай/-тәй
аю.. зур
-ын/-ен
ике.. бәйрәм
буш.. бирү
кыш.. кайту
-лай/-ләй
-лата/-ләтә
-лап/-ләп
яшьләр.. киенү
яхшы.. эшләү

***Игътибарыгыз өчен рәхмәт!***

